РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14 декабрь, 2023 ел Кукмара ш. № 226

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 29 октябрендәге 85 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 29 октябрендәге 85 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәгә (2021 елның 17 декабрендәге 95 номерлы, 2022 елның 24 августындагы 141 номерлы һәм 2023 елның 27 апрелендәге 195 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

4.31 пунктның бишенче абзацында «V бүлек белән» сүзен «VII бүлек белән» сүзләренә алыштырырга.

Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны кушымта итеп бирелгән яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2023 елның 14 декабрендәге 226 номерлы карарына кушымта

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле өчен мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. ЕГРН алып бару, күчемсез милекне дәүләт кадастр исәбенә алуны гамәлгә ашыру, күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән килешүләрне дәүләт теркәве, ЕГРНда булган мәгълүматларны бирү өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу буенча функцияләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимиятнең органы тарафыннан «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218 нче номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән мәгълүматлары Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында (алга таба – ЕГРН) саклана торган җир кишәрлеге чигенең урнашуына карата җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталарын билгеләү төгәллеге (уртача квадрат хатасы) кыйммәтләреннән артып киткән зурлыкка җир кишәрлеге чигенең характерлы ноктасы урынының тайпылышы.

2. Авыл хуҗалыгына бәйле булмаган әйберләр белән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең җир кишәрлеге мәйданының 20 һәм аннан да күбрәк процентын чүпләү.

3. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең җир кишәрлегендә авыл хуҗалыгы җитештерүен алып бару яки авыл хуҗалыгы җитештерүе белән бәйле башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кулланылмавын күрсәтә торган, мелиоратив саклагыч урман утыртмаларыннан тыш, чүп үләннәре һәм (яки) күпьеллык җиләк-җимеш агачларына карамаган агач-куаклык үсемлекләре белән каплануы.

4. Кукмара муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына (алга таба – Палата) физик зат милкендә, бер үк вакытта түбәндәге шартлар булганда кимендә 4 гектар бер яки берничә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлеге булу факты турында мәгълүмат керү:

- күрсәтелгән җир кишәрлекләренең һәрберсе әлеге физик затның милкендә өч елдан артык тора;

- әлеге физик зат авыл хуҗалыгы җитештерүе буенча эшчәнлек алып баручы крестьян (фермер) хуҗалыгы әгъзасы, юридик затның катнашучысы (оештыручысы) яки шәхси эшмәкәр түгел, яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен күрсәтелгән затларга милеккә һәм файдалануга тапшырмаган.

5. Палатага физик зат милкендә, бер үк вакытта түбәндәге шартлар булганда гомуми мәйданы кимендә 4 гектарлы бер яки берничә җир кишәрлеге булу факты турында мәгълүмат керү:

- күрсәтелгән җир кишәрлекләренең һәрберсе әлеге физик затның милкендә өч елдан артык тора;

- әлеге физик зат Татарстан Республикасы белән уртак административ чикләре булмаган Россия Федерациясенең башка субъекты (Татарстан Республикасы түгел) территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән;

- җир кишәрлекләре башка затларга бер елдан артык вакытка биләмәгә яисә куллануга тапшырылмаган.

6. Юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан тарафыннан файдаланыла торган контроль чара уздыру нәтиҗәсендә билгеләнгән җир кишәрлеге мәйданының, аның турында мәгълүматлары ЕГРНда, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларда булган җир кишәрлеге мәйданына туры килмәве.

7. ЕГРНда юридик зат, шәхси эшмәкәр, граждан кулланган җир кишәрлегенә хокуклар турында мәгълүмат булмау.

8. Мондый җир кишәрлеге хуҗасы булган затның мондый җир кишәрлегенә милек хокукын дәүләт теркәвенә алу датасыннан соң өч ел узгач, торак яки башка төзелеш өчен билгеләнгән җир кишәрлегендә капиталь төзелеш объектларын төзү белән бәйле капиталь төзелеш объектларының, төзелеш эшләре алып барылмау.

9. Палатага әйләнеше «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль закон белән көйләнә торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән булган җир кишәрлегенең максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмавы яисә Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланылуы турында аны максатчан билгеләнеше буенча кулланмау яки Россия Федерациясе законнарын бозып куллану сәбәпле  тартып алу турында суд карары нигезендә ачык сату нәтиҗәләре буенча яңа милекче мондый җир кишәрлеген сатып алган мизгелдән соң бер ел узгач, мәгълүмат керү.

10. Дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, иҗтимагый сервитут билгеләмичә кулланылган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлеген рөхсәт ителгән файдалану төренә туры китереп куллану мондый җирләрдә һәм (яки) җир ки алдагы алты ай дәвамында түбәндәге эшләр тәмамлану турында белешмәләр булганда мөмкин түгеллеге турында Палатага мәгълүмат керү:

инженерлык эзләнүләре үткәрү;

линияле объектны капиталь яки агымдагы ремонтлау;

вакытлы яки ярдәмче корылмалар (шул исәптән коймалар, көнкүреш корылмалары, түбәләр) төзү, федераль, региональ яки җирле әһәмияттәге линия объектларын төзүне, реконструкцияләүне тәэмин итү өчен төзелеш һәм башка материалларны, техниканы туплауны;

җир асты байлыкларын геологик тикшеренүләр үткәрү;

товар аквакультурасын (товар балыкчылыгын) гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән капиталь булмаган каралтылар, корылмалар төзү.

11. Шул ук кадастр кварталы чикләрендә урнашкан башка җир кишәрлеген аның теге яки бу категория җирләргә каравы һәм (яки) рөхсәт ителгән кулланылышка яраклы рәвештә максатчан билгеләнү буенча кулланмаган өчен яисә, мондый җир кишәрлеген билгеләнгән вакыт эчендә куллану бурычы Федераль закон белән каралган очракта, торак яки башка төзелеш, бакчачылык, яшелчәчелек өчен билгеләнгән җир кишәрлеген күрсәтелгән максатларда кулланмаган өчен, җир кишәрлегенең хокук иясен административ җаваплылыкка тарту турында Палатада мәгълүмат булу.»